| СОВЕТ ЮРТОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**КАРАР**

**№1** **20.06.2024ел**

**ҖИРЛЕ САЛЫМНАР СУММАЛАРЫ ӨЛЕШЕНДӘ БУРЫЧНЫ ТҮЛӘТҮГӘ ӨМЕТСЕЗ ДИП ТАНУНЫҢ ӨСТӘМӘ НИГЕЗЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА**

**1 статья. Әлеге карарны җайга салу предметы**

Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгели.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» әлеге карары бер үк вакытта җирле салымнар суммалары өлешендә түләтүгә өметсез дип танылган бурычны исәптән чыгару тәртибе булып тора.

**2 статья. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре**

2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түбәндәге нигезләр буенча түләп бетерү һәм (яисә) түләтү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләтүгә өметсез дип таныла:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирасны кабул итмәгән очракта, мирас ачылган көннән алып бер ел эчендә вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар карамагындагы бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамлангач, физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу;

4) салым түләүче бөлгенлек (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда булмаса, физик затларның җирле салымнар буенча бурычы барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы, аларны исәптән чыгару турында Карар кабул ителгән көнгә аларның күләме 100 (йөз)сумнан артмый;

5) "Бөлгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге №127-ФЗ Федераль закон нигезендә гражданны банкрот дип тану -

күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисапларны тәмамлау йомгаклары буенча түләнмәгән һәм күрсәтелгән Федераль законның 5 статьясы нигезендә агымдагы түләүләргә карый торган җирле салымнар буенча бурыч өлешендә;

6) РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел № 647 Указы буенча 2022 елның 1 сентябренә җирле салымнар буенча бурыч өлешендә салым түләүчене мобилизацияләү, әмма аларны исәптән чыгару турында карар кабул ителгән көнгә мондый бурыч күләменнән артык түгел.

**3 статья. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар**

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Карарның 2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) Россия Федерациясе Салым кодексының 11.3 статьясындагы 2 п. һәм 3 п. нигезендә салым органнары тарафыннан исәпкә алуның танылган рәвеше дип танылган бердәм салым счетының тискәре сальдосы турында белешмәләр;

б) физик затның вафат булуына бәйле рәвештә салым органнарында исәптән төшерелүе турында белешмәләр;

в) мирас алу хокукы турында таныклык бирү турында белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.

2) әлеге карарның 2 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) Россия Федерациясе Салым кодексының 11.3 статьясындагы 2 п. һәм 3 п. нигезендә салым органнары тарафыннан исәпкә алуның танылган рәвеше дип танылган бердәм салым счетының тискәре сальдосы турында белешмәләр;

б) салым юкка чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр.

3) әлеге карарның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) Россия Федерациясе Салым кодексының 11.3 статьясындагы 2 п. һәм 3 п. нигезендә салым органнары тарафыннан исәпкә алуның танылган рәвеше дип танылган бердәм салым счетының тискәре сальдосы турында белешмәләр;

4) әлеге карарның 2 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) Россия Федерациясе Салым кодексының 11.3 статьясындагы 2 п. һәм 3 п. нигезендә салым органнары тарафыннан исәпкә алуның танылган рәвеше дип танылган бердәм салым счетының тискәре сальдосы турында белешмәләр;

5) әлеге карарның 2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) Россия Федерациясе Салым кодексының 11.3 статьясындагы 2 п. һәм 3 п. нигезендә салым органнары тарафыннан исәпкә алуның танылган рәвеше дип танылган бердәм салым счетының тискәре сальдосы турында белешмәләр;

б) граждан мөлкәтен сатуны тәмамлау турында Арбитраж судының законлы көченә кергән билгеләмәсе күчермәсе (тиешле Арбитраж судының герб мөһере белән таныкланган яисә Россия Федерациясе Федераль арбитраж судларының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «арбитраж судлары карарлары банкы» сервисы ярдәмендә алынган).

6) әлеге карарның 2 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) Россия Федерациясе Салым кодексының 11.3 статьясындагы 2 п. һәм 3 п. нигезендә салым органнары тарафыннан исәпкә алуның танылган рәвеше дип танылган бердәм салым счетының тискәре сальдосы турында белешмәләр;

б) РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел № 647 Указы буенча Россия Оборона министрлыгыннан салым органнары тарафыннан алынган мобилизацияләнгән затлар буенча белешмәләр.

2. Салым органы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 5 пункты нигезендә кабул ителгән бурычны түләтүгә өметсез дип танылган бурычны түләтүнең расланган тәртибендә китерелгән форма буенча түләтүгә өметсез дип тану һәм түләтү мөмкин булмаган бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителергә мөмкин.

**4 статья. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге Советының "Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" карарының үз көчен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге Советының 2021 елның 06 октябрендәге №1 "Җирле салымнар буенча недоимка суммаларын, шул салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану өчен нигезләр билгеләү турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья. Әлеге карарның үз көченә керүе**

1) Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2) Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Ю.Кадыров